Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Осинники авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

“01” июнь 2021 ел № 25

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 22 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр " сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 4 пунктына « муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Осинники п., Яшьләр ур., 9А йорт (административ бина);

- Осинники п., Лесная ур., 2 йорт (Осинники мәдәният йорты),

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге башлыгы,
Осинники авыл җирлеге Советы рәисе А.Х. Сәгъдиев